**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ИЖЕВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

2022 елның 5 декабреннән № 76

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль
районының Ижевка авыл
җирлегендә бюджет процессы
турында нигезләмәгә үзгәрешләр
кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Ижевка авыл җирлеге Советы

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Ижевка авыл җирлеге Советының 2022 елның 22 мартындагы 56 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Ижевка авыл җирлегендә бюджет процессы турында нигезләмәнең 15 статьясындагы 2 пунктының 1 пунктчасын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Евразия икътисадый берлеге хокукы һәм таможня җайга салуы турында Россия Федерациясе законнары белән каралган бюджет дефицитын финанслау чыганаклары буенча керемнәрне һәм түләүләрне (бюджетның бердәм счетындагы калган акчалар белән идарә итү операцияләреннән, бердәм салым түләүләренә бәйле операцияләрдән, Евразия икътисадый берлеге хокукы һәм Россия Федерациясе законнары белән мәҗбүри түләүләргә карата каралган аванс түләүләренә бәйле операцияләрдән, каралган акчалата залогка бәйле операцияләрдән тыш) планлаштыруны (фаразлауны) гамәлгә ашыра.

2. Әлеге карарны Ижевка авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырырга һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында "Ижевка авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Ижевка авыл җирлеге рәисе урынбасары Р.М.Вәлеев